# КАРАР

**“19” ноябрь 2019 ел** **№ 6**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Ташкичү авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 19 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Ташкичү авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән, 1 нче һәм 2 нче төркем инвалидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча тубәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- юл-урам челтәренә вак таш түшәү (Ленин урамы – 70 м); юл-урам челтәре нигезен вак таш-грунттан каплау (Нариман урамы – 50 м, 1 нче номерлы йорттан башлап Ташкичү-Кысна юлы ягына таба);
- рөхсәтсез чүплекне каплау һәм бетерү; балалар мәйданчыкларына кече архитектура формалары сатып алу; урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;
- зиратны карап тоту өчен җиһазлар сатып алу (бензинлы чапкыч-1 данә);
- су куу башнясы урнаштыру; су башнясы насосы сатып алу-1 данә.

«ӘЙЕ» “КАРШЫ“

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 294 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 156 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 154 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Ташкичү авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Ташкичү авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән, 1 нче һәм 2 нче төркем инвалидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- юл-урам челтәренә вак таш түшәү (Ленин урамы – 70 м); юл-урам челтәре нигезен вак таш-грунттан каплау (Нариман урамы – 50 м, 1 нче номерлы йорттан башлап Ташкичү-Кысна юлы ягына таба);

- рөхсәтсез чүплекне каплау һәм бетерү; балалар мәйданчыкларына кече архитектура формалары сатып алу; урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;

- зиратны карап тоту өчен җиһазлар сатып алу (бензинлы чапкыч-1 данә);

- су кую башнясы урнаштыру; су башнясы насосы сатып алу-1 данә.

“ӘЙЕ”                    “КАРШЫ”

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Ташкичү авылы, Ленин урамы, 53 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы                    Ф. Х. Фәйзуллин